| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ ТУЕМБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТУЕМБАШ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Туембаш

31 июль 2024 года №23

**Туембаш авыл җирлегеҗирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Туембаш авыл җирлеге Уставы нигезендә Туембаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Туембаш авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген, гомуми булмаган файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә юл эшчәнлеге.

2. Кукмара муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Туембаш авыл җирлегеБашкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Туембаш авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында Туембаш авыл җирлегеСоветы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка житкерелгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Туембаш авыл җирлегенең икътисадый һәм бюджет-финанс мәсьәләләре комиссиясенә йөкләргә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Гарипов